СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

19.05.2025 ел Алабуга шәһәре № 429

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районының муниципальара хезмәттәшлек оешмаларында катнашу тәртибе турында» 2011 елның 29 апрелендәге 96 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

**КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2011 елның 29 апрелендәге 96 карары белән расланган Алабуга муниципаль районының муниципальара хезмәттәшлек оешмаларында катнашу тәртибе түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. 1) муниципаль берәмлекләр берләшмәләрендә муниципаль берәмлекләр әгъзалыгы;

2) муниципальара хуҗалык җәмгыятьләрен, муниципальара матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм челтәр басмасын оештыру;

3) муниципаль берәмлекләр тарафыннан коммерциягә карамаган оешмалар оештыру;

4) шартнамәләр һәм килешүләр төзү..».

Алабуга муниципаль районы Советы җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне бергәләп хәл итү өчен гавами булмаган акционерлык җәмгыятьләре һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр рәвешендә муниципальара хуҗалык җәмгыятьләре оештыру турында карарлар кабул итә ала.

Муниципальара оешмалар коммерциячел булмаган автоном оешмалар һәм фондлар рәвешендә төзелергә мөмкин.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль төзелеш, хокук тәртибе һәм законлылык, шәһәр төзелеше, инфраструктура үсеше һәм торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыру мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Г.П. Баганов